ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 10 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2023 елның 23 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2206-VI ДС

Проект

Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты –
Татарстан Республикасы Рәисе

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗАКОНЫ**

**2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында**

**1 статья**

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба шулай ук – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 79 575 893,1 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән – 68 413 312,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 10 002 880,7 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 79 575 893,1 мең сум итеп.

2. 2025 һәм 2026 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2025 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 84 537 640,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 10 143 269,8 мең сум һәм 2026 елга 89 761 460,3 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 10 394 665,3 мең сум итеп;

2) 2025 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 84 537 640,7 мең сум һәм 2026 елга 89 761 460,3 мең сум итеп.

**2 статья**

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2024 елга әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) 2025 һәм 2026 еллар план чорына әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

**3 статья**

Фонд бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә;

2) 2025 һәм 2026 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә.

**4 статья**

Фонд бюджетын үтәгәндә әлеге Закон белән расланган күләмнәрдән тыш фактта алынган һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры китереп, Фонд бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**5 статья**

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**6 статья**

1. 2024 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 8 582 309,4 мең сум итеп, 2025 елга 9 176 223,8 мең сум итеп, 2026 елга 9 790 030,9 мең сум итеп билгеләргә.

2. Нормалаштырылган иминият запасы акчалары түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны медицина ярдәменә түләү өчен җитешми торган акчаларны «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше нигезендә иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар ясауга;

3) квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

4) медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашуга;

5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте

программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре киметелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

**7 статья**

Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар нормативын мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 0,95 процент күләмендә билгеләргә.

**8 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^1$ пункт нигезендә 2024 елда Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр булып түбәндәгеләр тора дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү;

2) 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^2$ пунктның өченче – алтынчы абзацларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертү;

3) 2024 елга бюджет ассигнованиеләрен әлеге Законда «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе, «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү» максатчан статьясы буенча каралган бюджетлар чыгымнары классификациясе чыгымнары төрләре арасында 2024 елда чыгымнарның күрсәтелгән бүлеге, бүлекчәсе һәм максатчан статьясы буенча бюджет ассигнованиеләрен файдаланганда экономияләү хисабына яңадан бүлү;

4) 2024 елда Фонд бюджетына әлеге Закон белән расланган 2024 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән тыш медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелергә тиешле акчалар керү.

**9 статья**

Фонд бюджетының агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган, бюджет турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш булмаган акчалары, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фондның җыелма бюджет язуына тиешенчә үзгәрешләр кертеп, Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында Территориаль

мәҗбүри медицина иминияте программасы үтәлешен, квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын, иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәменә түләүне финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә дип билгеләргә.

**10 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**2024 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 79 575 893,1 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган кире кайтарылмый торган кертемнәр | 79 575 893,1 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 71 510 264,9 |
| 395 2 02 50203 09 0000 150 | Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 1 937 252,5 |
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 68 413 312,4 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 159 700,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 159 700,0 |
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 8 065 628,2 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 8 065 628,2 |
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 8 065 628,2 |
| | Керемнәр, барлыгы | 79 575 893,1 |

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | План чоры | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026ел |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 84 537 640,7 | 89 761 460,3 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган кире кайтарылмый торган кертемнәр | 84 537 640,7 | 89 761 460,3 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 76 361 641,7 | 81 365 518,7 |
| 395 2 02 50203 09 0000 150 | Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 1 967 270,8 | 1 998 723,7 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 73 154 651,6 | 78 044 014,5 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 239 719,3 | 1 322 780,5 |
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 239 719,3 | 1 322 780,5 |
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 8 175 999,0 | 8 395 941,6 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 8 175 999,0 | 8 395 941,6 |
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 8 175 999,0 | 8 395 941,6 |
| | Керемнәр, барлыгы | 84 537 640,7 | 89 761 460,3 |

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

**2024 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү**

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 324 010,5 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 324 010,5 |
| Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 324 010,5 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 324 010,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 324 010,5 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 324 010,5 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| финанс белән тәэмин итү | | | | | | |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләүләргә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 216 860,2 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 102 590,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 60,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 499,8 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 79 104 989,2 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 115 896,6 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 115 896,6 |
| Федераль (региональ) проектлар | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 54 807,7 |
| «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 0000 0 | | 54 807,7 |
| Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация белән хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | | 54 807,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | 300 | 54 807,7 |
| Процессны чаралар комплекслары | 395 | 09 | 04 | 01 4 00 0000 0 | | 61 088,9 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0000 0 | | 61 088,9 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 0 | | 61 088,9 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | | 61 088,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 61 088,9 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 78 989 092,6 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 78 989 092,6 |
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 09 | 09 | 01 4 00 0000 0 | | 78 989 092,6 |
| «Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0000 0 | | 3 086 668,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | | 3 086 668,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | 300 | 3 086 668,1 |
| «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0000 0 | | 409 943,0 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | | 409 943,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | 300 | 409 943,0 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0000 0 | | 75 492 481,5 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 0 | | 6 243 479,6 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | | 4 306 227,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 4 306 227,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | | 1 937 252,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | 300 | 1 937 252,5 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафынан күрсәтелгән медицина ярдәме | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | | 1 159 700,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | 300 | 1 159 700,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 0 | | 68 089 301,9 |
| Татарстан Республикасында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | | 66 211 301,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | 300 | 66 211 301,9 |
| Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | | 1 878 000,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | 500 | 1 878 000,0 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 146 893,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 146 893,4 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 146 893,4 |
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 10 | 03 | 03 4 00 0000 0 | | 146 893,4 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесслы чаралар комплексы | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0000 0 | | 146 893,4 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | | 141 943,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | 300 | 141 943,1 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | | 14,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | 300 | 14,7 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | | 1 263,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | 300 | 1 263,3 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | | 3 672,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | 300 | 3 672,3 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 79 575 893,1 |

«2024 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымта

**2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү**

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | План чоры | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | 2025 ел | 2026 ел |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 336 605,1 | 350 069,3 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 336 605,1 | 350 069,3 |
| Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 336 605,1 | 350 069,3 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 336 605,1 | 350 069,3 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 336 605,1 | 350 069,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оештыруны финанс белән тәэмин итү | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 336 605,1 | 350 069,3 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләүләргә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 224 654,5 | 233 640,6 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 106 979,6 | 111 265,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 60,0 | 60,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 911,0 | 5 103,4 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 84 048 266,5 | 89 252 511,1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 116 476,8 | 117 089,5 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 116 476,8 | 117 089,5 |
| Федераль (региональ) проектлар | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 54 807,7 | 54 807,7 |
| «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 0000 0 | | 54 807,7 | 54 807,7 |
| Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация белән хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | | 54 807,7 | 54 807,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 N1 5554 0 | 300 | 54 807,7 | 54 807,7 |
| Процессны чаралар комплекслары | 395 | 09 | 04 | 01 4 00 0000 0 | | 61 669,1 | 62 281,8 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процессны чаралар комплексы | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0000 0 | | 61 669,1 | 62 281,8 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 0 | | 61 669,1 | 62 281,8 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гамәлгә ашыру | | | | | | | |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | | 61 669,1 | 62 281,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 61 669,1 | 62 281,8 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 83 931 789,7 | 89 135 421,6 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 83 931 789,7 | 89 135 421,6 |
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 09 | 09 | 01 4 00 0000 0 | | 83 931 789,7 | 89 135 421,6 |
| «Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0000 0 | | 3 141 270,2 | 3 302 868,2 |
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | | 3 141 270,2 | 3 302 868,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | | | | | | | |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | 300 | 3 141 270,2 | 3 302 868,2 |
| «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0000 0 | | 414 061,8 | 418 375,0 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | | 414 061,8 | 418 375,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | 300 | 414 061,8 | 418 375,0 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы» | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0000 0 | | 80 376 457,7 | 85 414 178,4 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 0 | | 6 318 691,9 | 6 397 452,7 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | | 4 351 421,1 | 4 398 729,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | | | | | | | |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 4 351 421,1 | 4 398 729,0 |
| Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | | 1 967 270,8 | 1 998 723,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | 300 | 1 967 270,8 | 1 998 723,7 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафынан күрсәтелгән медицина ярдәме | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | | 1 239 719,3 | 1 322 780,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | 300 | 1 239 719,3 | 1 322 780,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 0 | | 72 818 046,5 | 77 693 945,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белән тәэмин итү | | | | | | | |
| Татарстан Республикасында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | | 70 810 464,5 | 75 551 855,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | 300 | 70 810 464,5 | 75 551 855,2 |
| Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | | 2 007 582,0 | 2 142 090,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | 500 | 2 007 582,0 | 2 142 090,0 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 152 769,1 | 158 879,9 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 152 769,1 | 158 879,9 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 152 769,1 | 158 879,9 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 10 | 03 | 03 4 00 0000 0 | | 152 769,1 | 158 879,9 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесслы чаралар комплексы | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0000 0 | | 152 769,1 | 158 879,9 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | | 147 620,8 | 153 525,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | 300 | 147 620,8 | 153 525,6 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | | 15,3 | 15,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | 300 | 15,3 | 15,9 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | | 1 313,8 | 1 366,4 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | 300 | 1 313,8 | 1 366,4 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | | 3 819,2 | 3 972,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | 300 | 3 819,2 | 3 972,0 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 84 537 640,7 | 89 761 460,3 |

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын (алга таба – закон проекты) формалаштыру бюджет турындагы законнар таләпләре һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» һәм «Эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертеме тарифы күләме һәм аны хисаплап чыгару тәртибе турында» федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырылды.

Чираттагы финанс елына, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба - Фонд) бюджетының төп характеристикалары 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең фараз күрсәткечләре нигезендә төзелде.

Фонд бюджеты күрсәткечләрен хисаплап чыгару 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән 3 815, 0 мең кеше, шул исәптән эшләмәүче 2 031,3 мең кеше санынннан чыгып гамәлгә ашырылды.

Фонд бюджеты керемнәренең гомуми күләме түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга –79 575,9 млн.сум;

2025 елга – 84 537,6 млн.сум;

2026 елга – 89 761,5 млн.сум.

Фонд бюджеты керемнәре өлешенең төп чыганаклары булып Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды субвенцияләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар тора

2024 елда планлаштырыла торган керемнәрнең шактый өлеше (86,0%) Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының эшләүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен эш бирүчеләрдән тотып калына торган иминият акчаларыннан һәм Россия Федерациясе субъектының эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен иминият кертемнәреннән торучы субвенциясе белән тәэмин ителәчәк.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субвенцияләр түбәндәге күләмдә билгеләнә:

2024 елга – 68 413,3 млн. сум;

2025 елга – 73 154,6 млн. сум;

2026 елга – 78 044,0 млн. сум.

Субвенциянең күләме арту түбәндәгеләргә акча бүлеп бирүне күздә тота:

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы нигезендә табиблар һәм урта медицина персоналы буенча эш хакының төбәктә хезмәт эшчәнлегеннән алына торган айлык уртача керемгә карата чагыштырмасын саклауга;

башка чыгымнарны (медикаментлар, тотыла торган материаллар, туклану, коммуналь һәм башка хезмәт күрсәтүләр) 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразының төп макроикътисадый параметрлары нигезендә арттыруга;

онкология авырулары булган затларга клиник тәкъдимнамәләр һәм дәвалау беркетмәләре нигезендә медицина ярдәме күрсәтүне финанс белән тәэмин итүгә.

Фонд бюджетында исәпкә алынган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар суммалары 2024 елга – 10 002,9 млн.сум, 2025 елга – 10 143,3 млн.сум һәм 2026 елга 10 394,7 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәгеләргә:

мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәменә түләүгә – 2024 елда – 3 086,7 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә 3 141,3 млн.сум һәм 3 302,9 млн.сум;

медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә – 2024 елда – 1 937,3 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 1 967,3 млн.сум һәм 1 998,7млн.сум;

бер каналлы финанслау кысаларында медицина ярдәме күрсәтүгә – 2024 елда – 4 306,2 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 4 351,4 млн.сум һәм 4 398,7 млн.сум;

санитария авиациясенә, иминләштерелмәгән халыкка ашыгыч медицина ярдәменә – 115,9 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 117,1 млн.сум;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга – 2024 елда – 409,9 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 414,0 млн.сум һәм 418,4 млн.сум;

гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә – 2024 елда – 146,9 млн.сум, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 158,9 млн.сум.

Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге күләмдә планлаштырыла:

2024 елга – 1 159,7 млн.сум;

2025 елга – 1 239,7 млн.сум;

2026 елга – 1 322,8 млн.сум.

Фонд бюджеты чыгымнары, хезмәт өчен түләү фондын һәм агымдагы чыгымнарны арттыру индексларын исәпкә алып, 2024 елга – 79 575,9 млн.сум күләмендә билгеләнә, ул 2025 һәм 2026 еллар план чорына тиешенчә 84 537,6 млн.сум һәм 89 761,5 млн.сум тәшкил итәчәк.

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләренә түләүгә акчаны түбәндәгечә җибәрергә планлаштырыла:

2024 елда – 79 251,9 млн.сум;

2025 елда – 84 201,0 млн.сум;

2026 елда – 89 411,4 млн.сум.

Фондның программаларга кертелмәгән чыгымнары түбәндәге күләмдә карала:

2024 елда – 324,0 млн.сум;

2025 елда – 336,6 млн.сум;

2026 елда – 350,1 млн.сум.

Закон проекты белән иминләштерүче медицина оешмалары эшен алып баруга чыгымнар нормативы мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмаларына кергән акчалар суммасыннан 0,95 проценты күләмендә күздә тотыла.

Мәҗбүри медицина иминияте системасының тотрыклылыгын тәэмин итү өчен Фонд бюджетында Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләме 2024 елга – 8 582 309,4 мең сум, 2025 елга – 9 176 223,8 мең сум, 2026 елга 9 790 030,9 мең сум итеп билгеләнде. Бу акчалар түбәндәгеләргә җибәреләчәк:

медицина ярдәменә түләү өчен җитешми торган акчаны иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында каралган күләмдә исәп-хисап ясауга;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре кимителүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

2024 елда, 2025 һәм 2026 еллар план чорында Фонд бюджеты баланслана һәм кытлыксыз планлаштырыла.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, гамәлләре туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә яңалары кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законын кабул ителүгә бәйле рәвештә кайсы да булса Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокук актларының үз көчен югалтуын тану, гамәлләрен туктатып тору, үзгәрешләр кертү яки яңаларын кабул итү таләп ителмәячәк.

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Закон проекты белән 2024 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) бюджетының керемнәр өлешен – 79 575,9 млн.сум, 2025 һәм 2026 еллар план чорына тиешенчә 84 537,6 млн.сум һәм 89 761,5 млн. сум күләмендә расларга тәкъдим ителә.

Фонд бюджетының керемнәр өлеше чыганаклары булып Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Федераль фонд) субвенцияләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Россия Федерациясе субъектларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар тора.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Федераль фонд бюджетыннан субвенцияләр күләме түбәндәгеләрдән чыгып хисаплап чыгарылды:

субъектта 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән 3 815 046 кеше саныннан («Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затлар саны турында мәгълүматлар» дигән 8 нче форма мәгълүматлары буенча);

территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын финанс белән тәэмин итүнең «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» федераль закон проекты белән билгеләнгән 2024 елга – 17 932,5 сум, 2025 елга – 19 175,3 сум, 2026 елга 20 456,9 сум күләмендә билгеләнгән нормативыннан.

Субвенция түбәндәге күләмдә фаразлана:

2024 елга – 68 413,3 млн.сум;

2025 елга – 73 154,6 млн.сум;

2026 елга – 78 044,0 млн.сум.

Фонд бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар күләме «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты белән каралган (шул исәптән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга) күләмнәргә туры килә:

медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасында билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүне – 2024 елга, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 1 937,3 млн. сум, 1 967,3 млн. сум һәм 1 998,7 млн. сум;

медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны (мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәменә түләүне кертеп) – 2024 елга, 2025 һәм 2026 елларга тиешенчә – 7 918,7 млн. сум, 8 023,2 млн. сум һәм 8 237,1 млн. сум;

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү буенча адреслы социаль ярдәм чараларын – 2024 елга, 2025 елга һәм 2026 елга тиешенчә – 146,9 млн.сум, 152,8 млн.сум, 158,9 млн.сум.

Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан бюджетара трансфертлар, 2020 – 2022 елларда акча кертемнәре динамикасын һәм 2024 – 2026 елларга индекс-дефляторларны исәпкә алып, түбәндәге күләмдә планлаштырыла:

1 159,7 млн.сум - 2024 елга;

1 239,7 млн.сум - 2025 елга;

1 322,8 млн.сум - 2026 елга.

Закон проекты белән Фонд бюджетының чыгымнар өлешен түбәндәге суммада расларга тәкъдим ителә:

2024 елга –79 575,9 млн.сум;

2025 елга – 84 537,6 млн.сум;

2026 елга – 89 761,5 млн.сум.

Чыгымнар 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразының төп макроикътисадый параметрлары нигезендә хисаплап чыгарылды.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджетның чыгымнар өлеше федераль (региональ) проектлар һәм процесслы чаралар комплекслары буенча бүленде.

Медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация белән хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итү чыгымнары барлыгы түбәндәге суммадагы «Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» федераль проектын һәм процесслы чаралар комплексын үз эченә ала

2024 елга – 115,9 млн. сум;

2025 елга – 116,5 млн.сум;

2026 елга – 117,1 млн.сум.

«Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесслы чаралар комплексы түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга – 3 086,7млн. сум;

2025 елга – 3 141,3 млн.сум;

2026 елга – 3 302,9 млн.сум.

«Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесслы чаралар комплексы түбәндәге еларга планлаштырыла:

2024 елга – 409,9 млн. сум;

2025 ел – 414,0 млн.сум;

2026 ел – 418,4 млн.сум.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга – 75 492,5 млн. сум;
2025 елга – 80 376,4 млн.сум;
2026 елга – 85 414,2 млн.сум,
шул исәптән:

– 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга - тиешенчә 6 243,5 млн.сум, 6 318,7 млн.сум һәм 6 397,5 млн.сум;

– 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә - тиешенчә 68 089,3 млн. сум, 72 818,0 млн.сум һәм 77 693,9 млн.сум;

– Россия Федерациясенең башка субъектлары террит -ориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафынан күрсәтелгән медицина ярдәменә – тиешенчә 1 159,7 млн.сум, 1 239,7 млн.сум һәм 1 322,8 млн.сум.

Гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өлешендә «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесслы чаралар комплексы кысаларында түбәндәге күләмдә акча карала:

2024 елга – 146,9 млн.сум;
2025 елга – 152,8 млн.сум;
2026 елга – 158,9 млн.сум.

Дәүләт программалары белән каралмаган чыгымнар бюджетның программага кертелмәгән чыгымнары өлешен тәшкил итә.

2024 елда 2025 һәм 2026 еллар план чорына Фонд бюджеты баланслана һәм кытлыксыз планлаштырыла.